КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 14 апрель г.Казань № 405

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче; 2016 ел, 15 февраль, 73 нче; 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче; 2019 ел, 29 июль, 629 нчы; 2020 ел, 25 август, 737 нче; 2021 ел, 19 апрель, 257 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1197 нче; 2022 ел, 8 июнь, 540 нчы; 2022 ел, 16 август, 843 нче; 2023 ел, 17 март, 261 нче; 2023 ел, 30 август, 1040 нчы; 2023 ел, 13 ноябрь, 1469 нчы; 2023 ел, 12 декабрь, 1603 нче; 2024 ел, 27 май, 370 нче; 2024 ел, 24 июнь, 455 нче; 2024 ел, 27 декабрь, 1226 нчы; 2025 ел,

9 август, 583 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «41. | «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» бердәм дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – БЦП БДМ системасы) ятим балалар турында исәпкә алу мәгълүматының дөреслеген тәэмин итү, процент | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) опека һәм попечительлек органнары | квартал саен | О = (К × 0,3 + ИПД × 0,4 + ИСО × 0,3) × 100%,<br><br>монда:<br>К – исәпкә алу мәгълүматының дөреслек коэффициенты;<br>ИПД – мәгълүматлар тулылыгы индексы;<br>ИСО – үз вакытында яңарту индексы.<br>К компоненты түбәндәге формула буенча исәпләнә:<br><br>$К = \frac{D_1}{D_0}$,<br><br>монда:<br>$D_1$ – БЦП БДМ системасында ятим балалар турында дөрес, үз вакытында һәм тулы күләмдә рәсмиләштерелгән язмалар саны;<br>$D_0$ – исәпкә алынган ятим балаларның гомуми саны (хисап датасына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми мәгълүматлары буенча).<br>ИПД компоненты түбәндәге формула буенча исәпләнә:<br><br>$ИПД = \frac{F}{T}$,<br><br>монда:<br>F – БЦП БДМ системасында дөрес тутырылган мәҗбүри кырлар саны;<br>T – БЦП БДМ системасында мәҗбүри кырларның гомуми саны.<br>ИСО компоненты түбәндәге формула буенча исәпләнә:<br><br>$ИСО = \frac{A}{N}$,<br><br>монда:<br>A – БЦП БДМ системасында үз вакытында яңартылган язмалар саны;<br>N – БЦП БДМ системасында яңартылырга тиешле язмалар саны». |

2. Бу карар 2026 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин